КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 6 июль г.Казань № 558

Республика башкарма хакимият органнары төзелүнең 100 еллыгы турында

Республика башкарма хакимият органнары төзелүнең 100 еллыгы уңаеннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына, Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән берлектә, Татарстан Республикасы, шул исәптән Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары төзелү һәм формалашу тарихын массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту эшен дәвам итәргә.
2. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына 2020 елның 1 октябренә кадәр республика башкарма хакимият органнары төзелүнең 100 еллыгына багышланган китап чыгаруны тәэмин итәргә.
3. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты белән берлектә, 2020 елның 25 июленә кадәр республика башкарма хакимият органнары төзелүнең 100 еллыгы уңаеннан төзекләндерү (яшелләндерү) объектлары турында тәкъдимнәр кертергә.
4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына үз рәсми сайтларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең тиешле башкарма органы төзелү тарихын чагылдыра торган бүлек ясарга, җитәкчеләре турында мәгълүмат, тарихый документлар, белешмәләр, фотосурәтләр һәм башкаларны урнаштырырга.
5. Татарстан Республикасы үсешенә шактый өлеш керткән Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссиягә 2020 елның 25 июленә кадәр республика үсешенә шактый өлеш керткән Татарстан Республикасы Хөкүмәте әгъзалары истәлеген мәңгеләштерү турында тәкъдимнәр кертергә.

6. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары хезмәткәрләренә авыру балаларга ярдәм күрсәтү өчен бер көнлек эш хакын «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә күчерүне тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына бу карарның 6 нчы пункты нигезендә хезмәткәрләре акча күчерергә теләк белдерәчәк Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына мәгълүмати-консультация ярдәме күрсәтергә һәм кергән акчаны файдалануны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырырга.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе Ш.Х.Гафаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин